# Ислам нуры

«Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәтү бар»
(Коръән Кәрим. 2-256)

12+

№9 (733) 12 май 2021 ел (1442, Рамазан) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга


*2021 ел - Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы*

## УРАЗА ГАЕТЕ



Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

Әссәламүгаләйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Мөхтәрәм дин кардәшләрем! Кадерле милләттәшләрем!

Ничек кенә үкенечле булса да, һиҗри буенча 1442 елның Рамазан ае ахырына якынлашты. Хактыр ки, хәдисләрнең берсендә әйтелгәнчә, “Әгәр кешеләр Рамазан аеның бөтен фазыйләтләрен белсәләр, алар аның мәңге дәвам итүен теләрләр иде”. Ләкин алда безне бөек куаныч - Ураза гаете көтә. Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте һәм шәхсән үз исемемнән мин сезне чын күңелдән якынлашып килүче Гыйд әл-Фитр бәйрәме белән котлыйм!

Аллаһның киң рәхмәтләре һәм чиксез юмартлыгы белән сугарылган Рамазан аеның 30 көнен без уразаны намус белән тотып, Коръән укып, изге гамәлләр кылып һәм Раббыбыз ризалыгына ирешергә ашыгып уздырырга тырыштык. ИншаАллаh, Яралтучыбыз безнең гөнаһларыбызны кичергәндер һәм ихластан кылынган гыйбадәтләребезне, яхшы гамәлләребезне, чын йөрәктән чыккан тәүбәләрне кабул иткәндер. Хәдисләрнең берсендә: «Кыямәт көнендә ураза һәм Коръән кол өчен шәфәгать итәчәк. Ураза: “Раббым! Мин аны көндез ашау-эчүдән мәхрүм иттем, шуңа күрә аның өчен шәфәгать итәргә рөхсәт бир!” – диячәк. Ә Коръән: “Раббым! Мин аны төнлә йокыдан мәхрүм иттем, шуңа күрә аның өчен шәфәгать күрсәтергә рөхсәт бир!” – диячәк һәм аларның шәфәгатьне кабул ителәчәк”, – диелә.

Аллаһка ышанып, Аның ризалыгы өчен ураза тотып һәм төннәрен намазда үткәргән һәркем ярлыканыр, дип өметләник. Ураза гаете кебек олы бәйрәмдә без бу хакта Аллаһка ялварып догалар кылачакбыз.

Әмма Ураза бәйрәме җитте дип, Аллаһка гыйбадәтләрне калдыру дөрес булмас. Сөекле Пәйгамбәребез (с.г.в.): “Кем Рамазан аенда ураза тотса, һәм аннан соң Шәүвәл аенда алты көн ураза тотса, ул ел дәвамында ураза тоткан кебек булыр”, – дигән.

Шуңа күрә, газиз дин кардәшләрем, әйдәгез әле, үз-үзебезгә, соңгы көннәребезгә кадәр Аллаһның каннуннарына буйсынып яшәрбез, дип вәгъдә бирик. Әйдәгез, Ураза бәйрәмен саф калеб һәм күңел белән каршы алыйк, элекке гөнаһларыбызга кире әйләнеп кайтмаска һәм Рамазан аенда тәрбияләнгән яхшы гадәтләребезне үстерергә тырышыйк!

Барыбызның да Аллаһның ризалыгына һәм Аның мәрхәмәтенә, ике дөнья бәхетенә, ныклы иманга ирешүен һәм дин юлында эшләргә мөмкинлекләр артуын телим.

Аллаһы Тәгалә уразабызны һәм барлык яхшы гамәлләребезне кабул итсен! Әмин.

**Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН,** *Татарстан Республикасы мөфтие*

## ИМАН НУРЫ БИРСЕН!



Мәрхәмәтле, Рәхимле Аллаh исеме белән!
Мөхтәрәм дин кардәшләр!

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Чаллы шәһәре мөхтәсибәте һәм үз исемемнән барчагызны изге Рамазан ае тәмамланып, Гыйд әл-Фитр – Ураза бәйрәме җитүе белән ихлас котлыйм! Бу айда кылган барча изгелекләребез, тоткан уразаларыбыз, мохтаҗларга биргән хәер-сәдакаларыбыз, барча гыйбадәтләребез Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен булса иде дә, кабул ителеп, әҗер-савапларга ирешергә язса иде. Рамазан аенда ирешкәннәрне, күңелебезгә туплаган рухи кыйммәтләребезне киләчәктә дә саклый алсак иде.

Рамазан ае быел да озын көннәргә туры килде. Ошбу изге гамәлне үтәүдә зур сабырлык, күндәмлелек күрсәтүчеләр генә Аллаһы Тәгаләнең вәгъдә иткән бүләкләренә өметләнә алалар. Раббыбыз Аллаh әйтә: “Чынлап та, сабырларга исәпсез-хисапсыз әҗерләр бирелер” (39:10.) Аллаһы Тәгалә тоткан уразаларыбыз, укыган намазларыбыз, кылган барча изгелекләребез бәрәкәтендә тормышыбызны тагын да күркәмрәк итсен, изге ният-максатларыбызга ирешергә юлларын ачсын! Өйләребездә һәрвакыт тынычлык, татулык, муллык булсын! Илләргә, дөньяларга иминлек, адәм балаларының күңеленә иман нуры, тәннәренә саулык бирсен. Киләчәктә дә гыйбадәтләребез дәвамлы булып, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә лаек яшәргә насыйп әйләсен!

**Әлфәс хәзрәт ГАЙФУЛЛИН,**
*Чаллы шәһәре имам-мөхтәсибе,*
*ҮДО – ТҖМ ДН Президиумы әгъзасы*



## КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Газетабызның беренче битен бәйрәм котлавы белән әзерләп, типографиягә җибәрер алдыннан гына республиканы канлы вакыйга тетрәндерде. Казанның 175 нче мәктәбендә булган вакыйга уңаеннан мөфти Камил хәзрәтнең инстаграм битендә уртаклашкан кайгынамәсен тәкъдим итәбез.

“Мөбарәк Рамазан аен һәм бөтен илебезне коточкыч хәл тетрәндерде - Казанның бер мәктәбендә атыш булды. Үлүчеләр һәм яраланганнар арасында балалар да, өлкәннәр дә бар. Бу вәхшилек күңелне телә һәм өшетә. Фаҗигадән барча татарстанлыларның да күңелләре сыкрана, йөрәкләребез ярсый һәм телгәләнә. Укучы һәм укытучыларның якыннары хәзерге мизгелләрдә кичергән тирән борчуларын сүз белән әйтеп бетереп булмый! Нәзарәт һәм республиканың 1500 имамы исеменнән, шулай ук шәхсән үз исемемнән бу хәсрәт кагылып киткән барлык гаиләләрнең тирән кайгысын уртаклашам. Республикакүләм ифтарда, шулай ук мәчетләрдә бүген һәм иртәгә шушы канкойгыч фаҗигадә һәлак булганнар рухына һәм яраланганнарга дога кылыначак - алар аңа мохтаҗ. Ихластан Бөек Раббыбыздан имгәнгәннәргә Үзенең шифасын бирүен һәм үлгәннәрне Үзенең киң рәхмәтеннән аермавын үтенеп сорыйм: “Без Аллаһыдан килдек һәм Аңа әйләнеп кайтачакбыз”. Әмин”.

Рамазан аеның 29нчы көнендә (11нче майда) Татарстан мәчетләрендә Казан мәктәбендә килеп чыккан фаҗигадә вафат булучыларның рухына дога кылдылар. Аллаһы Тәгалә илебезне, дөньяны мондый коточкыч хәлләрдән Үзе сакласын. Дога кылу шулай ук Татарстанның йөз мәчетендә үтте.

# ПӘЙГАМБӘРНЕҢ МИГЪРАҖ КЫЛУЫ

Кадерле дин кардәшләрем!

Без сезнең белән Пәйгамбәребез (с.г.в.)нең тормышына багышланган хөтбәләрдә аның дәгъват белән Таиф шәһәренә баруын, әмма таифлеләрнең ислам динен кабул итмәүләрен, Пәйгамбәребез (с.г.в.)не мәсхәрәләп таш атып куууларын, хәтта таш атып аякларын канатуларын белгән идек. Пәйгамбәребез (с.г.в.)нең ни кичерүен күз алдына китерегез! Дәгъват кылуына инде 10 ел була, әмма мәккәлеләрнең күбесе ислам динен кабул итми, аның үзен дә, сәхәбәләрен дә эзәрлеклиләр. Таянычы булган иң якын кешеләрен - Әбү Талиб белән Хәдичәне югалта. Инде менә Таиф шәһәрендә аны кабул итмиләр.

Нәкъ менә шушы вакытта бик мөһим бер могҗиза була. Нинди могҗиза? Ни өчен мөһим ул? Бу могҗизаны соңыннан "Мигъраҗ", ягъни "Төнге сәяхәт" дип атыйлар.

Аллаһның Илчесе (с.г.в.) бер төн эчендә җаны-тәне белән Мәккәдән Бәйтүл Мәкъдискә, аннан Аллаһы Тәгалә хозурына күтәрелә. Мәккәдән Бәйтүл Мәкдискә кадәр 1239 чакрым. Икегә тапкырласак, бу 2478 чакрым була. Ул чорда бу кадәр ерак араны шулай тиз үтү - Аллаһы Тәгаләнең могҗизасы гына түгел, шулай ук җитди сынавы да. Шул вакытта яшәгән мөселманнар өчен ныклыкка имтихан. Шулай ук безнең һәм бездән соң киләчәк буыннар өчен дә имтихан бу. Ни өченме? Чөнки бу вакыйгага ышанырга кирәк. Ышанмый торган кешеләр төркеме дә бар. Бу вакыйгага гына түгел, хәтта Аллаһның барлыгына ышанмыйлар алар! Менә шушы кешеләр мөселманнарның җаннарында ул вакытта бер төн эчендә бу кадәр ерак араны үтеп булмый дигән шик-шөбһә тудырырга тырышалар. Төрле дәлилләр китерәләр. Ә без моңа каршы, Аллаһы Тәгалә ни теләсә, шуны эшли ала, дип җавап бирәбез. Аллаһы Тәгалә безнең иманыбызны, кайчандыр сәхәбәләрнең иманын сынаган кебек, сынап карарга тели.

Пәйгамбәребез (с.г.в.) бу кичне Мәккәдә өмме Хани йортында булган, аның янына Җәбраил фәрештә килә. Шуннан Аллаһның Илчесе (с.г.в.) урыныннан кузгала да, Кәгъбә янына китә. Кәгъбә тирәли 7 тапкыр тәуаф кыла. Аңа әл-Бурак дип аталган хайванны китерәләр. Бу хайван ак төстә, ишәктән биегрәк, аттан тәбәнәгрәк була. Ул күз күреме кая җитсә, шунда күчерә ала. Ягъни бер урыннан икенче урынга бик тиз күчә. Һәм Пәйгамбәребез (с.г.в.) бу хайванга утырып, Әл-Әкъса мәчетенә барып җитә. Аллаһы Тәгалә бу турыда болай ди: "Үзенең колы Мөхәммммәд галәйһисәламне аятьләребездән кайберләрен күрсәтер өчен төнлә Мәккә шәһәрендәге Хәрам мәчетеннән тирә-ягын бәрәкәтле иткән Әл-Әкъса мәчетенә күчерүче Аллаһы Тәгаләне һәр кимчелектән пакь дип белегез! Һичшиксез, ул Ишетүче, Күрүче" ("Әл-Исра", 17:1).

Әл-Әкъса мәчетенә килеп җиткәч, Пәйгамбәребез (с.г.в.) Буракны мәчетнең капкасына бәйләп куя. Сорау: ни өчен ул аны мәчет капкасына бәйләп куя? Беренчедән, безгә күрсәтер һәм безне өйрәтү өчен: сәбәбен кылсаң, нәтиҗәсен күрерсең. Максатка ирешү өчен бөтен көчне куеп тырышырга кирәк. Бурак качып китү ихтималы бармы әллә? Яки аны кемдер алып китә аламы? Юк! Ул моны "Берни эшләмәсәң дә, көч түкмәсәң дә, максатыңа ирешә аласың" дигән кешеләр барлыкка килмәсен өчен эшли. Шуңа күрә, җәмәгать, максатыңа ирешүеңә ышанычың булса да, нәтиҗәле булсын өчен бөтен көчеңне куярга кирәк. Пәйгамбәребез (с.г.в.) безгә моны үзенең мисалында ачык күрсәтте. Икенчедән, Пәйгамбәребез (с.г.в.) мөселман өммәтенең Әл-Әкъса мәчете белән тыгыз бәйләнештә булуын күрсәтергә тели. Бурак Әл-Әкъса мәчетенә бәйләнгән кебек, без дә бу мәчеткә бәйләнгән булырга тиешбез.

Шуннан Аллаһның Рәсүле мәчеткә керә. Һәм ул анда ни күрә? Кайчандыр бу дөньяга килеп киткән барча пәйгамбәрләр монда җыелган! Күз алдына китерегез! Гасырлар дәвамында кешеләргә килгән барлык пәйгамбәрләр бер мәчеттә җыелганнар. Безнең Пәйгамбәребез (с.г.в.) аларга имам булып баса һәм алар белән ике рәкагатьтән торган җәмәгать намазы укый. Бу пәйгамбәрләрнең безнең Пәйгамбәребез (с.г.в.)гә Әл-Әкъса мәчетен тапшыруларын күрсәтә. Моннан соң Аллаһның ихтыяры буенча, барлык кешеләрнең имамы Рәсүлүллаһ (с.г.в.) булачак. Һәм шулай ук Ибраһим (г.с.)нең дингә чакыру үзәге булган ике шәһәр - Мәккә һәм Иерусалим аның хакимлеге астында булачак. Һәм шул мизгелдән Әл-Әкъса мәчете бары тик мөселманнарныкы гына булырга тиеш. Чөнки Әл-Әкъса мәчете кешеләргә гасырлар дәвамында җибәрелгән пәйгамбәрләр белән бәйле. Шуңа күрә Пәйгамбәребез (с.г.в.) Әл-Әкъса мәчетен мөселманнар территориясенә кушарга тырыша, шулай ук моны Әбү Бәкер дә эшләргә тырышып карый, һәм, ниһаять, Гомәр бине Хаттаб идарә иткәндә аны мөселман җирләренә кушалар.

Пәйгамбәребез (с.г.в.) җәмәгать намазын үткәргәннән соң Җәбраил (г.с) белән Иерусалимнан күккә күтәрелә башлый. Пәйгамбәребез (с.г.в.) сөйли: "Без күкнең беренче катына күтәрелгәч, Җәбраил беренче кат күкнең капкасын какты, һәм аңа ачтылар,"- ди. Бу күкләрнең капкасы барлыгын күрсәтә. Башта аннан: "Кем?" - дип сорадылар. Җәбраил: "Җәбраил", - дип әйтте. "Ә синең белән кем?" "Минем белән Мөхәммәд". "Аны инде җибәрделәрмени", - дип сорадылар: "Әйе", - дип җавап бирде", - ди.

Шуннан алар күкнең беренче катына керәләр. Пәйгамбәребез (с.г.в.) сөйли: "Мин анда озын буйлы кешене күрдем, уңга карагач, ул шатлана, ә сулга карагач, елый иде. Мин Җәбраилдән: "Кем бу?"- дип сорадым. Ул миңа: "Бу синең атаң - Адәм". "Ни өчен ул болай эшли?" - дип сорагач, Җәбраил: "Уңга карагач, ул иман китерүчеләрне күрә, һәм шатлана, чөнки алар котылучылар, ә сулга карагач, һәлак булачак имансызларның җаннарын күрә" - дип җавап бирде", - ди.

Ә хәзер игътибар итегез! Адәм шайтан белән арасында булган вакыйгадан гыйбрәт алган кешеләргә карап шатлана. Алар гыйбрәт алып, шайтанның вәсвәсәсенә бирелмичә: "Шайтан мине алдамас, һәм мине Җәннәттән мәхрүм итмәс. Мин аның вәсвәсәсенә бирелмим!" - диюче Җәннәт әһелләредер.

Әмма, кызганычка каршы, битараф кешеләр дә булыр. Алар шайтан артыннан ияреләр. Шайтан Адәм белән Һаваны Җәннәттән мәхрүм иткән кебек, аларны да Җәннәттән мәхрүм калдырыр. Минем сезгә шайтанның кайбер юлларын әйтеп үтәсем килә. Белегез, шайтанның максатларының берсе - кешеләрне теләсә нинди юл белән аерудыр. Вәсвәсәгә бирелгән Адәм белән Һаваны Җәннәттә ничек аеруын исегезгә төшерегез әле. Аллаһы Тәгалә әйтә: "Һәм алар икесе дә ул агачтан татып карагач, гаурәтләре ачылды, һәм алар өсләренә Җәннәт яфраклары ябыштыра башладылар" ("Әл-Әгъраф", 7:22).

Карагыз, шайтан кешене чишендерергә, тагын да ныграк хурлыкта калдырырга омтыла. Ә корәйшитләрне ничек котырта ул? "Ничек сез оялмыйча Аллаһның кушканнарын үтәмәгән, Аллаһка буйсынмыйча, гөнаһлар кылып йөргән киемнәрегез белән, Кәгъбә тирәли тәуаф кыла аласыз?" - ди. Һәм карагыз, корәйшитләр Пәйгамбәребез (с.г.в.) пәйгамбәр итеп җибәрелгәнче Кәгъбә тирәли шәрә көе тәуаф кыла иделәр! Карагыз, шайтан кешене ничек иттереп төрле сылтаулар белән чишендерергә тырыша. Җәннәттә Адәм белән Һавага: "Бу агачның җимешен ашасагыз, мәңге яшәрсез, бар нәрсәгә ия булырсыз", - дип вәсвәсәләп чишендереп, Җәннәттән мәхрүм итсә, корәйшитләргә башка яктан килә: "Аллаһның кушканнарын үтәмәгән, Аңа буйсынмыйча гөнаһлар кылып йөргән киемнәрегез белән ничек тәуаф кыла аласыз?" - ди. Хәзерге заманда шайтан "Мода" сүзе аша килә. "Мода" сүзен кулланып, хатын-кызларны чишендерә, ирләргә сыланып торган чалбарлар кидертә. Шуңа күрә, белегез, кем "Мода", "Цивилизация", яки "Цивилизацияле кием" дигән сүзләр астында шайтанга иярә, менә шуларга карап Адәм галәйһи сәлам елый. Чөнки алар аталары Адәм (г.с.) кыйссасына карап гыйбрәт алмаганнар, Адәм югалткан кебек, Җәннәтне югалтканнар.

Шуннан Пәйгамбәребез (с.г.в.) күкнең икенче катына күтәрелә. Икенче кат күктә ул Гайсә белән Яхья (г.с.)не күрә. Мөселманнар фикеренчә, Гайсә тәрегә кадаклап үтерелмәгән, Аллаһ аны Үз хозурына күтәргән. Һәм Кыямәт көне алдыннан җиргә төшерәчәк. Пәйгамбәребез (с.г.в.) Адәм (г.с.)не сәламләгән кебек аларны да сәламли.

Аннан күкнең өченче катына күтәрелә. Анда Йосыф (г.с.)не күрә. Әйе, кол итеп сатылган, бу дөньяның ярты матурлыгы бирелгән Йосыфны. Җәмәгать, Йосыфның әбисе Сара да бу дөньяның иң чибәр хатыннарыннан булган. Пәйгамбәребез (с.г.в.): "Аллаһ Һавадан кала Сарадан да матуррак хатын-кызны яралтмаган," - ди. Хуҗасының хатынын аздыруда гаделсез гаепләнеп, төрмәгә ябылган; үзе дә, әтисе, бабасы да пәйгамбәр булган; бик күп сынаулар үтеп, ахыр чиктә дәүләт башлыгы дәрәҗәсенә күтәрелгән Йосыф (г.с.) белән күрешә. Аннан күкнең дүртенче катына күтәрелә. Анда Идрис (г.с.)не сәламли һәм күкнең бишенче катына күтәрелә. Монда Мусаның туганы Харун (г.с.) белән очраша. Аннан күкнең алтынчы катына күтәрелеп, Муса (г.с.) белән күрешә. Белегез, Аллаһы Тәгалә Үзенең Коръәни Кәрим китабында иң күбе Муса (г.с.) турында сөйли. Муса (г.с.) турында сөйләнгән кыйссаларда бик күп гыйбрәтләр бар. Ул Фиргәвеннән, үзенең халкыннан бик күп золымлык күргән. Шуңа күрә аны Аллаһы Тәгалә күкнең алтынчы катына урнаштырып, дәрәҗәсен күтәргән. Һәм ул Аллаһы Тәгалә белән турыдан-туры сөйләшүче пәйгамбәрләрнең берседер. Муса (г.с)не сәламләгәч, Пәйгамбәребез (с.г.в.) кузгала, ә Муса (г.с) елый башлый. Пәйгамбәребез (с.г.в.): "Нәрсә сине еларга мәҗбүр итә?" - дип сорагач, Муса (г.с): "Минем өммәтемә карый, миннән соң җибәрелгән егетнең өммәтеннән Җәннәткә күбрәк кеше кергәнгә елыйм мин", - дип җавап бирә. Шуннан Җәбраил (г.с) Пәйгамбәребез (с.г.в.) белән күкнең җиденче катына күтәрелә. Анда бөтен пәйгамбәрләрнең атасы, Аллаһның сөекле пәйгамбәре Ибраһим Хәлил белән күрешәләр. Яратуның иң югары дәрәҗәсе хилла дип атала. Хәлил сүзе хилла сүзеннән ясалган. Пәйгамбәребез (с.г.в.) Ибраһим (г.с)гә сәлам бирә. Соңыннан Пәйгамбәребез (с.г.в.) Ибраһим (г.с)не тасвирлаганда: "Барыннан да бигрәк ул сезнең иптәшегезгә охшаган", - дип үзенә күрсәтә. Шуннан соң ул "Сидрату мунтәһә" (ахыр чик лотосы) дигән җиргә күтәрелә. Бу урында барча җан ияләре һәм аларның гыйлеме тәмамлана, шуңа аны шулай атыйлар, Пәйгамбәребез (с.г.в.) ул җирне: "Ул төрле төстәге матур нурлар белән балкып тора. Һәм кеше бу кадәр матурлыкка түзә алмый. Аның яфраклары фил колагы кадәр зурлыкта", - дип тасвирлый. Бу мәһабәт агач күкнең җиденче катыннан да биегрәк. Аллаһы Тәгалә бу турыда болай ди: "Ул Җәбраилне (Мигъраҗ кичәсендәге) иңүендә соңгы чиктәге Сидерәтүлмүнтәһә агачы булган бакчада күргән иде. Мәэва җәннәте шул агач янындадыр. Ул вакытта Сидерәтүлмүнтәһә агачын (алтын саранчалармы, фәрештәләр төркемеме, яки Аллаһның әмереме) каплаган иде. Аның (Рәсүлнең) күзе читкә тайпылмады һәм читтән узмады" ("Ән-Нәҗм", 53:13-17). Аның янында Җәннәт бакчасы. Аллаһтан анда кертүен сорыйбыз. Бу агачның матурлыгы бөтен тирә-юньне биләп алуга карамастан, Пәйгамбәребез (с.г.в.) авышмады. Аннан Пәйгамбәребез (с.г.в.) тагын да югарырак күтәрелә, хәтта: "Мин бу дөньяның язмышын язучы каурыйларның шыкырдавын ишеттем", - ди.

Күз алдына китерегез, нинди бөек дәрәҗәгә җитә Пәйгамбәребез (с.г.в.)! Һәм шушы югары дәрәҗәгә күтәрелгәч, Аллаһы Тәгалә аның белән сөйләшә башлый.

**Әбүбәкер хәзрәт ӘБДИЕВ**,
*Чаллының "Тәүбә" мәчете имам-хатыйбы*

## БЕЛӘСЕЗМЕ?

* Ураза гаете – Исламда Рамазан ае тәмамлану хөрмәтенә билгеләнгән зур бәйрәм. Аның тарихы Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в) заманына – 624 елга ук барып тоташа. Пәйгамбәребез (с.г.в) Мәдинәдә булганда ураза тота башлыйлар һәм бер айлык ураза тәмамлангач, аны бәйрәм итәләр. Пәйгамбәребез (с.г.в) үз мисалында ниләр эшләргә икәнен күрсәтеп калдырган.

* Гаеткә ничек әзерләнергә соң? - Гает алдыннан юынырга кирәк. Мунча керү - күркәм гамәл. Иң матур, чиста күлмәкләрне киеп, бәйрәмгә – Гает намазына барырга кирәк.

* Фитыр сәдакасын мескеннәргә, ятимнәргә һәм фәкыйрьләргә акчалата да,ризыклата да бирергә мөмкин. Рамазан аенда сәдака бирү бик фазыйләтле. Чөнки фитыр ул аерым сәдака, ә нәфел сәдакасын аерым бирергә кирәк.

* Фитыр сәдакасын гаеткә кадәр бирергә кирәк. Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтә: “Кем дә кем гаеткә кадәр фитыр сәдакасын бирсә, ул фитыр сәдакасы дип саналыр һәм безнең хатакимчелекләребезне, гөнаһларыбызны Аллаһы Тәгалә гафу итәр, кичерер”. Гаеттән соң бирсәк, ул гади сәдакалардан булыр. Шуңа күрә фитыр сәдакасын гаеткә кадәр бирү хәерлерәк. Әмма гаеткә кадәр бирергә өлгермәгәнсез икән, кул селтәмәгез, барыбер бирегез, ниятегез чиста булсын. Гади сәдака булып саналса да, савабы булыр.

* Гаетнең тагын бер әдәбе - зиратларга бару, каберлекләрне чистарту һәм дога кылу. Әтиәниләр, әби-бабайлар исән булса, алар янына барып, хәлләрен белешү, коймак һәм башка таба ашлары пешереп, аларны кунак итү хәерле. Балаларыбызны да гает белән котлап, аларга да бүләкләр бирсәк, кечкенәдән гаетне танып, белеп үсәрләр.

* Ураза гаете өч көн бәйрәм ителә. Гаеттән соң тагын уразага керергә була. Рамазан ае тәмамлангач, Шәүвәл аенда тагын 6 көн ураза тотсак, бер ел ураза тоткан кебек савап языла. Гаетнең икенче көнендә ураза тотарга ярамый, аннан соң дәвам итәргә мөмкин.

* Рамазан аенда теге яки бу сәбәп белән калган уразаларны гаеттән соң ук тотарга да ярый, тик башта Шәүвәл ае уразасын тоту хәерлерәк.

* Ураза тотмаган өчен, уразаны калдырган өчен сәдаканы ураза аенда бирү хәерлерәк.

* Сәдаканы кул белән бирмичә, төрле хәйрия чараларына, авыру балаларга да күчерергә ярый. Күп әйбер нияттән тора. Аның һәрберсе сәдака дип санала.

* Ураза гаете көнне бер-береңне бәйрәм белән котлау – матур гадәт. Исәнлек-саулык, бәрәкәт, озын гомерләр теләргә һәм Раббыбыз шушы тоткан уразаларыбызны кабул кылсын дияргә кирәк. Чөнки Пәйгамбәребез (с.г.в.) вакытында сәхәбәләр әйтә: “Без уразаны тоткач, ярты ел буе “Йә, Раббым, уразамны кабул кыл” дип, икенче яртыеллыкта “икенче уразаны күрергә насыйп кыл” дип дога кыла идек, ди. Ураза гаете – бик зур бәйрәм. Сабырлыкның тантана итү көне.

### ӘДӘБИ СҮЗ

*Рәзинә МӨХИЯР*

### *ШИФАЛЫ ЯҢГЫР*

*Ураза – шифалы яңгыр,*
*Җан-тәнне ул чистарта.*
*Ураза - Аллаһ рәхмәте,*
*Бу айда иман арта.*
*Ел буе җыелып килгән*
*Гөнаһлар да юыла.*
*Рамазан күпме кешене*
*Китерә дин юлына?!*
*Нәфесләр дә богаулана,*
*Ураза тоткан чакта.*
*Мохтаҗны, ачны аңлыйсың*
*Үзең ач булган чакта.*
*Ураза безне өйрәтә*
*Чыкмаска ызан-чиктән.*
*Чистара күңел шулхәтле,*
*Төшкәндәй гел бишектән.*

*ГАМЬЛЕ ӘҢГӘМӘ*

## “КИЛЕННӘР ҮЗЛӘРЕНЕҢ ДӘ КАЕНАНА БУЛАЧАГЫН ОНЫТА”

*Соңгы вакытта социаль челтәрләрдә каенаналарыннан зарланып язылган хатлар күзгә чалына башлады. Гаеп атта да, тәртәдә була анысы. Тик менә үпкәләшмичә, бер-береңнең хәтерен калдырмыйча ничек үзара дус булып яшәргә?.. Әңгәмәбез барышында Татарстанның баш казые **Җәлил хәзрәт ФАЗЛЫЕВ** сабыр итү турында кат-кат искә төшереп сөйләде. Бер генә сүз белән әйткәндә, олысына да, кечесенә дә сабыр булырга кирәк.*

– Килен белән каенана проблемасы бүген генә килеп чыкмаган. Элек тә булган, бүген дә бар. Хәзер рәхәткә чыктык. Интернетта утырабыз, кулдан телефон төшми. Әби-бабайлар чорында андый нәрсә юк иде. Тиз генә кемгәдер шалтыратып, йә ватсаптан язып зарлана алмаганнар. Ул шунын белән күпереп тә китмәгән, үзләрендә калдырганнар. Бүген килен каенанасыннан зарлана, унбиш-егерме елдан ул үзе дә каенана булачак бит. Шуны онытып җибәрәләр. Пәйгамбәребез (с.г.с.) дә: “Берәү дә үзе кылганны бу дөньядан күрми китмәс”, – дигән. Әти-әни дә әби-бабай белән яшәде, без дә 34 ел өлкәннәр белән бер өйдә гомер иттек. Бүген килен белән торабыз. Дүрт буын бергә яшәгән вакыт та булды. Тормышта барысы да була, өйдәге капкадан гына ары китәргә тиеш түгел ул. Инстаграмда язып зарланалар, ә аңардан берәр нәрсә үзгәрәме? Юк шул. Ә менә бераз гына хәйләкәррәк һәм тәмле телле булсаң, үзара мөнәсәбәтләрне тиз җайлап була. Равилә Шәйдуллинаның “Карт шомырт хатирәсе” дигән әсәрендә килен белән каенана арасындагы нечкә мөнәсәбәтләр бик матур сурәтләнә. Бер эпизод аеруча истә калган. Килен умач уган, әмма бик эре килеп чыккан. Аш бүлгәндә моны күреп, каенана киленне сүгәргә дип талпынганда гына тегесе: “Әни бәгърем, кайчан синең кебек умачны вак итеп уарга өйрәнермен инде”, – дип куя. Менә шунда ничек итеп киленгә сүз әйтәсең инде?! Килен дипломат булмаса, тавыш чыга иде. Пәйгамбәребез (с.г.с.): “Берәү үзе хаклы булып юл куйган икән, аңа җәннәтнең уртасыннан урын булыр”, – ди. Ә безнең җәннәткә дә керәсе килә, юл да куясы, сүзне дә бирәсе килми. Хатын җәннәткә керсен өчен ирнең ризалыгын алырга кирәк. Ә ир кеше җәннәтле булсын өчен әтиәни ризалыгы мөһим. Маңгае тишелгәнче намаз укыса да, хаҗга барса да, елның 361 көнен ураза тотса да, хатын иренең ризалыгын алмыйча җәннәткә керә алмый. Каенана белән сүзгә кереп, ирен дә аңа каршы куйса, ул хатын үзен дә, тормыш иптәшен дә җәһәннәмгә алып бара булып чыга.

**– Бу дини гыйлем дә булмаудандыр?**

– Тәрбия дә, дини гыйлем дә булырга тиеш. Дини гыйлеме булган кайбер кызлар бик “остаралар”. Ир моны тиеш, тегене тиеш дип кенә утыралар. Безнең заманда дин көчле түгел иде. Аллага шөкер, безнең хатыннар динсез булса да, денсез булмаган. Ден ул шул әдәп-әхлак инде. Дини гыйлеме булмагач, хатыннар мал да карадылар, сыер да саудылар, бәби дә алып кайттылар, әти-әнине дә карап озаттылар. Аерым шартлар тудыр дип әйтүче булмады. Менә бүген бик “акыллылар”, әти-әни белән бергә яшиселәре дә, аларны карыйсылары да килми. Ә тәрбия ул гаиләдән килә. Әти-әнисенең әби-бабайга булган мөнәсәбәтен бала күреп үсә һәм аны гадәти күренеш итеп кабул итә, шулай тиеш дип белә. Ир белән хатын аерылышкан очракта, әнисе баласына әтисен гел яманлап-хурлап сөйли. Кыз бала булса, ул кияүгә чыккач, ирне хөрмәт итеп яшисен белми дә. Гел әйтә торган сүзем бар: яхшыны яхшыга кушкач кына әйбәт була. Пәйгамбәребез (с.г.с.)дән, син бу дөньяга ни өчен китерелдең дип сорагач, дин таратырга дими, гүзәл әхлакны тәмам булдырыр өчен, дип әйтә. Әхлакны кешеләрнең үзара мөнәсәбәтеннән белеп була. Ир белән хатын, килен белән каенана, туганнар арасындагы мөнәсәбәт – барысы да әхлакка барып тоташа. Намаз, ураза, хаҗ әхлак юлында инструмент булып тора. Намаз укучы әби-бабайларны күреп, алар тәрбиясендә үскән чор без. Инстаграмда утыручыларның күбесе исә намаз укымаучылардан туган буын.

**– Килен белән каенана арасындагы мөнәсәбәтләргә әйләнеп кайтыйк әле, хәзрәт. Үзара аңлашып яшәү өчен нәрсә җитми?**

– Никахларда яшь киленнәргә, тәмле телле булыгыз, дим. Тәмле сүз бөтен ачу, үпкәләшне юкка чыгара. Сабыр һәм акыллы булырга кирәк. Килен ир йортына килә. Анда каенана үзенчә яшәгән, үз эш тәртибе, үз көе белән йөри. Алга таба да шулай яшисе килә. Әмма килен дә территория бүлешә башлый. Аның да үзенчә буласы килә. Монда инде берсе акыллы булып, юл куярга тиеш. Килен йә каенана димим. Кайсы акыллы – шунысы. Икесе дә акылсыз булса, тавыш чыга. Шул ук вакытта килен дә үзенең каенана буласы кеше булуын истә чыгармаска тиеш. Ир-ат та чын дипломат булсын. Ул берсенең баласы, икенчесенең – ире. Мин үзем коры, усал булдым. Уртак дошман кешеләрне әйбәтрәк берләштерә. Әнине дә, хатынны да урынына куя белдем. Бу минем акыллы икәнне күрсәтми, ә алар акыллы булган. Аннары тавыш эш юктан чыга. Эшсез йөрсәң, тегесен дә, монысын да күрәсең. Эшләп арыган кешенең чәйнәшергә вакыты да, теләге дә калмый. Килен алгансың икән, йә кияүгә баргансың икән, тәкъдиреңә риза булып яшә. Ир дә, хатын да, каенана да – тәкъдир.

*Әңгәмәдәш* – **Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА** *(“Шәһри Казан”)*

# Июнь аена намаз вакытлары

| Милади июнь | Көн исеме | Шәүвәл, зөлкагъдә | Иртәнге намаз: Таң беленә Уфа | Таң беленә Чаллы | Таң беленә Казан | Мәчетләрдә укыла Уфа | Мәчетләрдә укыла Чаллы | Мәчетләрдә укыла Казан | Кояш чыга Уфа | Кояш чыга Чаллы | Кояш чыга Казан | Зәвәл Уфа | Зәвәл Чаллы | Зәвәл Казан | Өйлә Уфа | Өйлә Чаллы | Өйлә Казан | Икенде Уфа | Икенде Чаллы | Икенде Казан | Ахшам Уфа | Ахшам Чаллы | Ахшам Казан | Ястү Уфа | Ястү Чаллы | Ястү Казан |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Сш | 20 | 02:46 | 00:53 | 01:06 | 03:18 | 01:23 | 01:36 | 04:46 | 02:53 | 03:06 | 13:14 | 11:28 | 11:41 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:54 | 17:11 | 17:24 | 21:42 | 20:03 | 20:16 | 23:12 | 21:33 | 21:46 |
| 2 | Чш | 21 | 02:45 | 00:52 | 01:05 | 03:17 | 01:22 | 01:35 | 04:45 | 02:52 | 03:05 | 13:14 | 11:28 | 11:41 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:55 | 17:11 | 17:24 | 21:44 | 20:04 | 20:18 | 23:14 | 21:34 | 21:48 |
| 3 | Пҗ | 22 | 02:44 | 00:52 | 01:04 | 03:16 | 01:22 | 01:34 | 04:44 | 02:52 | 03:04 | 13:14 | 11:28 | 11:41 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:55 | 17:12 | 17:25 | 21:45 | 20:05 | 20:19 | 23:15 | 21:35 | 21:49 |
| 4 | Җм | 23 | 02:44 | 00:51 | 01:03 | 03:16 | 01:21 | 01:33 | 04:44 | 02:51 | 03:03 | 13:14 | 11:28 | 11:41 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:56 | 17:13 | 17:26 | 21:46 | 20:07 | 20:20 | 23:16 | 21:37 | 21:50 |
| 5 | Шм | 24 | 02:43 | 00:50 | 01:03 | 03:15 | 01:20 | 01:33 | 04:43 | 02:50 | 03:03 | 13:15 | 11:28 | 11:42 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:57 | 17:13 | 17:27 | 21:47 | 20:08 | 20:21 | 23:17 | 21:38 | 21:51 |
| 6 | Як | 25 | 02:42 | 00:49 | 01:02 | 03:14 | 01:19 | 01:32 | 04:42 | 02:49 | 03:02 | 13:15 | 11:29 | 11:42 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:57 | 17:14 | 17:27 | 21:48 | 20:09 | 20:22 | 23:18 | 21:39 | 21:52 |
| 7 | Дш | 26 | 02:41 | 00:48 | 01:01 | 03:13 | 01:18 | 01:31 | 04:41 | 02:48 | 03:01 | 13:15 | 11:29 | 11:42 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:58 | 17:15 | 17:28 | 21:49 | 20:10 | 20:23 | 23:19 | 21:40 | 21:53 |
| 8 | Сш | 27 | 02:41 | 00:48 | 01:00 | 03:13 | 01:18 | 01:30 | 04:41 | 02:48 | 03:00 | 13:15 | 11:29 | 11:42 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:58 | 17:15 | 17:28 | 21:50 | 20:11 | 20:24 | 23:20 | 21:41 | 21:54 |
| 9 | Чш | 28 | 02:40 | 00:47 | 01:00 | 03:12 | 01:17 | 01:30 | 04:40 | 02:47 | 03:00 | 13:15 | 11:29 | 11:42 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 18:59 | 17:16 | 17:29 | 21:51 | 20:12 | 20:25 | 23:21 | 21:42 | 21:55 |
| 10 | Пҗ | 29 | 02:40 | 00:46 | 00:59 | 03:12 | 01:16 | 01:29 | 04:40 | 02:46 | 02:59 | 13:16 | 11:29 | 11:42 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 19:00 | 17:16 | 17:29 | 21:52 | 20:13 | 20:26 | 23:22 | 21:43 | 21:56 |
| 11 | Җм | 1 | 02:39 | 00:46 | 00:59 | 03:11 | 01:16 | 01:29 | 04:39 | 02:46 | 02:59 | 13:16 | 11:30 | 11:43 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 19:00 | 17:17 | 17:30 | 21:53 | 20:14 | 20:27 | 23:23 | 21:44 | 21:57 |
| 12 | Шм | 2 | 02:39 | 00:46 | 00:58 | 03:11 | 01:16 | 01:28 | 04:39 | 02:46 | 02:58 | 13:16 | 11:30 | 11:43 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 19:01 | 17:17 | 17:30 | 21:53 | 20:14 | 20:28 | 23:23 | 21:44 | 21:58 |
| 13 | Як | 3 | 02:39 | 00:45 | 00:58 | 03:11 | 01:15 | 01:28 | 04:39 | 02:45 | 02:58 | 13:16 | 11:30 | 11:43 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 19:01 | 17:18 | 17:31 | 21:54 | 20:15 | 20:29 | 23:24 | 21:45 | 21:59 |
| 14 | Дш | 4 | 02:38 | 00:45 | 00:58 | 03:10 | 01:15 | 01:28 | 04:38 | 02:45 | 02:58 | 13:16 | 11:30 | 11:43 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 19:01 | 17:18 | 17:31 | 21:55 | 20:16 | 20:29 | 23:25 | 21:46 | 21:59 |
| 15 | Сш | 5 | 02:38 | 00:45 | 00:58 | 03:10 | 01:15 | 01:28 | 04:38 | 02:45 | 02:58 | 13:17 | 11:30 | 11:44 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 19:02 | 17:19 | 17:32 | 21:55 | 20:16 | 20:30 | 23:25 | 21:46 | 22:00 |
| 16 | Чш | 6 | 02:38 | 00:45 | 00:57 | 03:10 | 01:15 | 01:27 | 04:38 | 02:45 | 02:57 | 13:17 | 11:31 | 11:44 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 19:02 | 17:19 | 17:32 | 21:56 | 20:17 | 20:30 | 23:26 | 21:47 | 22:00 |
| 17 | Пҗ | 7 | 02:38 | 00:45 | 00:57 | 03:10 | 01:15 | 01:27 | 04:38 | 02:45 | 02:57 | 13:17 | 11:31 | 11:44 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 19:03 | 17:19 | 17:32 | 21:56 | 20:17 | 20:31 | 23:26 | 21:47 | 22:01 |
| 18 | Җм | 8 | 02:38 | 00:45 | 00:57 | 03:10 | 01:15 | 01:27 | 04:38 | 02:45 | 02:57 | 13:17 | 11:31 | 11:44 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 19:03 | 17:20 | 17:33 | 21:57 | 20:18 | 20:31 | 23:27 | 21:48 | 22:01 |
| 19 | Шм | 9 | 02:38 | 00:45 | 00:57 | 03:10 | 01:15 | 01:27 | 04:38 | 02:45 | 02:57 | 13:18 | 11:31 | 11:44 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 19:03 | 17:20 | 17:33 | 21:57 | 20:18 | 20:32 | 23:27 | 21:48 | 22:02 |
| 20 | Як | 10 | 02:38 | 00:45 | 00:57 | 03:10 | 01:15 | 01:27 | 04:38 | 02:45 | 02:57 | 13:18 | 11:32 | 11:45 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 19:03 | 17:20 | 17:33 | 21:57 | 20:18 | 20:32 | 23:27 | 21:48 | 22:02 |
| 21 | Дш | 11 | 02:38 | 00:45 | 00:58 | 03:10 | 01:15 | 01:28 | 04:38 | 02:45 | 02:58 | 13:18 | 11:32 | 11:45 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 19:04 | 17:20 | 17:34 | 21:57 | 20:19 | 20:32 | 23:27 | 21:49 | 22:02 |
| 22 | Сш | 12 | 02:39 | 00:45 | 00:58 | 03:11 | 01:15 | 01:28 | 04:39 | 02:45 | 02:58 | 13:18 | 11:32 | 11:45 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 19:04 | 17:21 | 17:34 | 21:58 | 20:19 | 20:32 | 23:28 | 21:49 | 22:02 |
| 23 | Чш | 13 | 02:39 | 00:45 | 00:58 | 03:11 | 01:15 | 01:28 | 04:39 | 02:45 | 02:58 | 13:18 | 11:32 | 11:45 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 19:04 | 17:21 | 17:34 | 21:58 | 20:19 | 20:32 | 23:28 | 21:49 | 22:02 |
| 24 | Пҗ | 14 | 02:39 | 00:46 | 00:59 | 03:11 | 01:16 | 01:29 | 04:39 | 02:46 | 02:59 | 13:19 | 11:32 | 11:45 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 19:04 | 17:21 | 17:34 | 21:58 | 20:19 | 20:32 | 23:28 | 21:49 | 22:02 |
| 25 | Җм | 15 | 02:40 | 00:46 | 00:59 | 03:12 | 01:16 | 01:29 | 04:40 | 02:46 | 02:59 | 13:19 | 11:33 | 11:46 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 19:04 | 17:21 | 17:34 | 21:58 | 20:19 | 20:32 | 23:28 | 21:49 | 22:02 |
| 26 | Шм | 16 | 02:40 | 00:47 | 00:59 | 03:12 | 01:17 | 01:29 | 04:40 | 02:47 | 02:59 | 13:19 | 11:33 | 11:46 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 19:04 | 17:21 | 17:34 | 21:58 | 20:19 | 20:32 | 23:28 | 21:49 | 22:02 |
| 27 | Як | 17 | 02:41 | 00:47 | 01:00 | 03:13 | 01:17 | 01:30 | 04:41 | 02:47 | 03:00 | 13:19 | 11:33 | 11:46 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 19:04 | 17:21 | 17:34 | 21:57 | 20:18 | 20:32 | 23:27 | 21:48 | 22:02 |
| 28 | Дш | 18 | 02:41 | 00:48 | 01:01 | 03:13 | 01:18 | 01:31 | 04:41 | 02:48 | 03:01 | 13:19 | 11:33 | 11:46 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 19:04 | 17:21 | 17:34 | 21:57 | 20:18 | 20:32 | 23:27 | 21:48 | 22:02 |
| 29 | Сш | 19 | 02:42 | 00:49 | 01:01 | 03:14 | 01:19 | 01:31 | 04:42 | 02:49 | 03:01 | 13:20 | 11:33 | 11:47 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 19:04 | 17:21 | 17:34 | 21:57 | 20:18 | 20:31 | 23:27 | 21:48 | 22:01 |
| 30 | Чш | 20 | 02:43 | 00:49 | 01:02 | 03:15 | 01:19 | 01:32 | 04:43 | 02:49 | 03:02 | 13:20 | 11:34 | 11:47 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 19:04 | 17:21 | 17:34 | 21:57 | 20:18 | 20:31 | 23:27 | 21:48 | 22:01 |

*Балалар өчен*

**Фәйрүзә МӨСЛИМОВА**

## ТАТАР ӘЛИФБАСЫ

Кәбестә, кыяр, кабак
Бакчада үсә безнең.
Мул булыр табыннарыбыз –
Җыеп алырбыз көзен.



Бик ышанабыз уңышка,
Көн дә сулар сибәбез.
Ләкин Аллаһ теләмәсә –
Берни булмый, беләбез.

*Саулыгым-байлыгым*

## ЭНҖЕ ЧӘЧӘК



Энҗе чәчәкнең хуш исеннән йөрәк мускуллары ныграк кыскара, организмда кан әйләнеше яхшыра, бөердәге кан тамырлары киңәя һәм бу бәвел күбрәк чыгуга китерә. Үсемлектән ясалган препаратлар, аеруча төнәтмәләр, йөрәк өчен файдалы. Дәвалану өчен энҗе чәчәкне чәчәк ата башлаган чорда җыярга кирәк. Глаукома булганда, 1/2 стакан вак итеп туралган кычыткан яфрагы һәм 1 чәй кашыгы ландыш чәчәге алалар. 1 аш кашыгы су өстәп, 8-9 көн караңгы урында тоталар. Аннары 1/2 чәй кашыгы аш содасы кушалар. Катнашманы көнгә 2 мәртәбә күзгә куеп торалар. Калкансыман биз эшчәнлеген җайга салу өчен, тигез күләмдә энҗе чәчәк, петрушка яфрагы, эт тигәнәге алалар. 1 аш кашыгы катнашманы, 1 стакан кайнар суга салып, 10 минут кайнаталар. Көнгә 3 мәртәбә 1әр аш кашыгы эчәләр. Йөрәк тибеше көчәйсә, 6-7 чәчәкне, 1 стакан суга салып, 1 сәгать төнәтәләр, көнгә 3 мәртәбә 1/4әр стакан эчәләр. Бәвелне тота алмаганда, 15 г энҗе чәчәкне, 1 стакан кайнар суга салып, 20-30 минут төнәтәләр. Бәвел кудыручы чара буларак, көнгә 3 тапкыр 2шәр чәй кашыгы эчәләр. Энҗе чәчәк көчле тәэсир итә торган үсемлекләр төркеменә керә. Аны тиешле микъдардан артык кулланырга ярамый. Энҗе чәчәктән әзерләнгән препаратлар кискен миокардит, эндокардит, бавыр һәм бөердә кискен авырулар булганда зыянлы.

**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР**
**Баш мөхәррир**
**Муллагалиева А. Г.**
**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45
* * *
**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, "Ислам нуры" дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның "Ислам нуры"ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән хатларда авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юлларга кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
islamgazeta@mail.ru

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Бу санның тиражы: 1100**
**Индексы 54149**

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга тапшырсагыз иде. "Ислам нуры"ның һәр саны кулдан-кулга күчеп, динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан саклануларыгызны сорыйбыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән "Ислам нуры" басмаханәсендә басылды.

**Нәшир, типография һәм редакция адресы:**
**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**

**Басарга кул куелды:**
**график буенча 12 май 16 сәг.**
**фактта 12 май 16 сәг.**
**Бәясе ирекле**